ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.07.2022 г. Заинск № 337

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2019 елның 17 декабрендәге 644 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Полиция хезмәткәрләре һәм эчке эшләр органнары хезмәткәрләренең балаларына социаль ярдәм күрсәтү максатында, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

## карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2019 елның 17 декабрендәге 644 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләвен формалаштыру һәм алу тәртибе» 2 нче кушымтасының Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләве күләмен исәпләү, билгеләү һәм үзгәртү тәртибе II өлешенең 4 нче абзацын түбәндәгечә бәян итәргә:

"Өч һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган гаиләләр, шулай ук полиция хезмәткәрләренең балалары өчен ата-аналар түләве күләме 50 процентка кими".

2. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2019 елның 17 декабрендәге 644 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 23 маендагы 249 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Р. Сәфәргалиев
3-27-42